**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Гремячка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

8 декабрь, 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Гремячка авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Гремячка авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2021 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 8 декабрендә узган гражданнар җыенының 5 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Гремячка авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Гремячка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 90 яшьтән өлкән гражданнардан гайре, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
2. Гремячка авыл авыл җирлеге чикләрендәге юлларны кышын һәм җәйге карап тоту.
3. Гремячка авылларындагы юлларны ремонтлау.
4. МТЗ-82 тракторы өчен өстәмә җиһазлар сатып алу коммуналь ОК-2500; ПКУ-09 төягеч һәм 0,8 м3 чүмеч
5. Авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм карап тоту; (тирән насослар сатып алу);
6. Авыл җирлеге чикләрендә урамнарны яктыртуны тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;(энергияне сак тоту яктырткычларын сатып алу)

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы,

Трой-Урай авылы,  Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама –буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт  адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе  муниципаль районының
Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы                                        Р.Х.Сафин